Нәсыйхәт

Җомга 21 декабрь 2012 №19

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы

## Яңалыклар

### ИНВАЛИДЛАР– ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

Хәйрия акциясе кысаларында Мамадыш мәдрәсәсе инвалидларга ярдәм итү оештырды. Аларга ашау ризыкларыннан торган пакетлар һәм корбан ите таратылды. Ярдәмгә мохтаҗ булганнар чарадан канәгать калдылар, рәхмәтләрен белдерделәр.

### “ӨМЕТ”НЕ ТЕРНӘКЛӘНДЕРЕШЕП

Мәдрәсә “Өмет” тернәкләндерү үзәгенә яшелчә һәм бәрәңге белән ярдәм итте. Әлеге ярдәмне ул үзенә бирелгән гошердән өлеш чыгарып күрсәтте.

### ТНВ “ПЛАНЕТА” БЕЗДӘ КУНАКТА

5нче декабрьдә мәдрәсәдә “ТНВ Планета” каналы булып китте. Ул мәдрәсә белән танышты һәм аның эшчәнлеге турында репортаж төшерде.

### СТИПЕНДИЯ БИЛГЕЛӘНДЕ

1нче декабрьдән Мамадыш мәдрәсәсе яхшы укучы шәкертләргә стипендия билгеләде. Укуларында яхшы нәтиҗәгә ирешкән студентлар һәр ай саен акчалата стипендия алачак һәм бүләкләнәчәк.

### ГАИЛӘЛӘР ҖЫЕНЫ

16нчы декабрьдә мәдрәсәдә яшь мөселман гаиләләре җыены үткәрелде. Әлеге чарада вәгазьләр сөйләнелде, видеофильм каралды, викторина үткәрелде. Мәҗлес азагында кунаклар чәй белән сыйланды.

### ПЛЕНУМДА КАТНАШТЫЛАР

Район мөхтәсибе Илһам хәзрәт һәм мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәтенең пленумында катнаштылар. Биредә үткән елга нәтиҗәләр ясалды, киләсе елга планнар билгеләнде.

# Кыямәт көне кайчан җитә?



**Җир шарында төрле бәла-казаларның, катаклизмнарның артуы кешелек дөньясын соңгы вакытларда бигрәк тә нык уйланырга мәҗбүр итә. Кайберләренең авызыннан: “Ахырзаман якынлашуы шушыдыр инде”,–дигән сүзләр чыга башлады. “Кыямәт көне җитәргә күп калмаган, ул 2012 нчы елга туры килә икән”,–диючеләр дә табылды. Бу сүзләргә ышаныргамы? Кыямәт көне кайчан була?**

Әлбәттә, һәр мөселман кеше Кыямәт көненең кубачагына ышанырга тиеш. Чөнки ул иманның җиде нигезенең берсе. Әмма аның кайчан булачагы бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм. Көннәрдән бер көнне Җәбраил фәрештә Пәйгамбәребездән (с.г.с.) сорады: «Кыямәт көне кайчан килер?» Рәсүлуллаһ (с.г.с.) җавап йөзеннән: «Соралучы, сораучы кебек, Кыямәт көненең кайчан киләчәген белмәс», – диде. Димәк, аның кайчан булачагын бары тик Аллаһ кына беләдер. Әгәр дә кеше: «Мин Кыямәт көненең кайчан киләчәген беләм!»–дисә, ул зур гөнаһка төшкән булыр.

Кыямәт көненең кечкенә галәмәтләре күбесе чынга ашкан инде. Пәйгамбәребез (с.г.с.) әйтте: “Ун галәмәт күренмичә кыямәт көне булмас. “Төтен, Дәҗҗәл, кешеләр белән сөйләшүче хайван, кояшның көнбатыштан чыгуы, Гайсә (г.с.) килүе, Яҗүҗ Мәҗүҗ кавеме, өч урында (көнбатышта, көнчыгышта, Гарәп ярымутравында) җир ишелүе, кешеләрне җыелу мәйданына куучы ут”. Әлеге билгеләрнең килү тәртибе хакында галимнәр арасында уртак фикер юк. Әмма әгәр дә беренчесе дөньяга килсә, алар бербер артлы унысы да хасил булырлар.

### ДӘҖҖӘЛ ФЕТНӘСЕ

Дәҗҗәл сүзе асылда «дәҗәлә» дигән тамырдан алынган, аның мәгънәсе «томалау», «каплау»дыр, хакыйкатьне батыйль-ялган илә томалаганы өчен Дәҗҗал дип исем кушылган. Пәйгамбәребезнең хәдисендә болай диелә: «Әгәр дә берәрегез, намазны тәмам кылып соңгы тәшәһһүдне әйтте исә, дүрт нәрсәдән Аллаһыга сыенсын: кабер газабыннан, җәһәннәм газабыннан, Дәҗҗалның фетнәсеннән, тереклек вә үлем фетнәсеннән»,–диде. Пәйгамбәребез (с.г.с.) Дәҗҗалны түбәндәге сыйфатлар белән сыйфатлаган: ул яшь кеше булыр, йөзе кызгылт, чәчләре тырпаеп торыр, фәкать бер күзе генә күрер. Буе кыска. Дәҗҗал Хорасан ягыннан чыгар. Аның артыннан җитмеш мең яһүд гаскәре иярер. Дәҗҗал дөньяга чыкканнан соң кырык көн генә яшәр. Әмма бөтен җир йөзен әйләнеп чыгарга өлгерер, фәкать Мәккә илә Мәдинәдә генә була алмас.

Дәҗҗалнең фетнәсе бик зур булыр. Пәйгамбәребез (с.г.с.) аның фетнәсеннән саклану чарасы буларак, хәтта аңа кызыксынып та карарга чыкмагыз дип кисәтте, чөнки шушы арада кеше аның фетнәсенә каршы тора алмас. Ул: «Мин сезнең Раббыгыз!»–дип, кешеләрдән иман китертер, үз гомерендә Раббысын танымаган, аңа итәгать итмәгән бәндәләр төркем-төркем булып Дәҗҗалны Аллаһ дип танырлар.

### ГАЙСӘ (Г.С.) НЕҢ КИЛҮЕ

Дәҗҗал Фәләстыйн ягына борылыр, Бәйт ал-Макдискә юл тотар. Шушы вакытта Мәрьям улы Гайсә яңадан бу дөньяга килер. Сурия мәмләкәтенең башкаласы Дамаск шәһәренең көнчыгыш тарафында урнашкан Ак манара янына төшәр. Аннары Бәйт әл-Макдискә юл тотар. Бу вакытта намаз укырга камәт төшерелер. Гайсә (г.с.) ошбу җәмәгатькә кереп, Мәхдигә оеп, намаз укыр. Намаздан соң ал-Акъса мәчетеннән чыккач, ул Дәҗҗалны күреп алыр. Гайсәне (г.с.) күрүгә Дәҗҗал зәгыйфьләнеп кача башлар.

**(Ахыры 2нче биттә).**

# Кыямəт көне кайчан җитə?

Əмма Гайсə (г.с) аны куып җитеп үз кылычы белəн һəлак итəр. Гайсə (г.с) идарə иткəн чорда җир йөзендə бəрəкəт вə муллык шулкадəр булыр ки, хəтта байлыкка беркемнең дə ихтыяҗы булмас. Ə Аллаһ ризалыгы өчен сəҗдə кылу дөньяда булган барлык байлыктан да кадерлерəк булыр. Ул чорда яшəгəн яһүдлəр һəм христианнар Гайсə (г.с)нең Аллаһының пəйгамбəре икəнлегенə барысы да иман китерерлəр. Тормыш азагында ул хаҗ кылыр. Гайсə (г.с) җир йөзенə килгəч Коръəн белəн хөкем итеп җиде ел гаделлек белəн идарə иткəннəн соң кырык яшендə бу фани дөньядан китəр. Ул Рəсүлебез (г.с.) янына күмелер. Гайсə (г.с.) вафат булгач, халыклар тагын имансызлыкка кайтырлар.

## ДУХАН-ТӨТЕН ЧЫГУЫ

Рəсүлебез (г.с.) əйтте: "Кыямəт килмəс, аның ун галəмəте килгəнче... Алар арасында ул духанны да искə алды" (Мөслим, 2901) Бүгенге көндə бу төтеннең сыйфатын һəм чыганагын төгəл итеп əйтеп булмый. Ул радиация дə булырга мөмкин, космостан чыккан үтергеч нур да булуы ихтимал. Ибн Гомəр (р.г) əйтте: "Духан чыгу кыямəт көненең якынаюын белгертүче галəмəттер. Ул күкне һəм җир белəн күк арасын тутырыр, Аллаһыга иман китергəн бəндəлəр өчен аның зыяны томан рəвешендə генə булып, имансыз бəндəлəрне тəмам газаплар".

## КОЯШНЫҢ КӨНБАТЫШТАН ЧЫГУЫ

Галимнəрнең фəнни аңлатмаларына күз төшерсəк, алар бу вакыйганы галəмнең киңəюенең соңгы ноктасына җитеп кире үз халəтенə кайту процессы белəн аңлаталар. Риваятьлəрдə күренгəнчə бу вакыйга алдыннан кояш күк йөзенə өч тəүлек калыкмыйча торыр. Өч көннəн соң гына ул янə күк йөзендə күренер. Əмма, гадəттəгечə ул көнчыгыштан калыкмас, бəлки барлык кешелəрне гаҗəплəндереп, көнбатыштан күренер. Бу күренештəн соң барлык халык, вакыйганың бары тик Аллаһтан икəнлегенə инанып, Раббыларына иман китерергə телəрлəр, əмма аларның иманнары кабул ителмəс. Кояшның мəгрибтəн чыгуы Коръəндə "əл-Əнгəм" сүрəсенең 158 нче аятендə тəфсиллəнгəн. Аллаһы Тəгалə əйтте: "... Раббыңның бəгъзе галəмəтлəре килгəн көндə һичкемнең иман китерүе файда бирмəс, һəм əүвəлрəк иман китергəн , лəкин хəрамнардан тəүбə итмəгəн вə фарызларын үтəмəгəн хəлдə яшəве файда бирмəс. Әйт: "Көтегез Аллаһының газабын!"- дип".

Шулай ук моның турында хəдислəрдə дə бəян кылынган. Мөхəммəд гəлəйһис сəлəм əйтте: "Кояш көнбатыштан чыкмыйча кыямəт көне җитмəс. Əмма килер бер көн, кешелəр аның нəкъ көнбатыштан чыкканын үз күзлəре белəн күрерлəр һəм Раббыларына иман китерергə телəрлəр. Лəкин бу вакытта инде Аллаһы Тəгалə аларның иман китерүлəрен һич кабул итмəс."

## ҖИР ЙӨЗЕНӘ КЕШЕЛӘР БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮЧЕ ХАЙВАННЫҢ ЧЫГУЫ

Бу вакыйга хакында Аллаһы Тəгалə "Кырмыска" сүрəсенең 82нче аятендə болай диде: "Вəгъдə ителгəн Кыямəт килсə, алар белəн сөйлəшə торган бер җан иясен җирдəн чыгарырбыз. Кешелəрнең кылган эшлəрен сөйлəр, əмма алар, əлбəттə, Безнең аятьлəребезгə иман китермəс булдылар!" Пəйгамбəребез (г.с.) əйтте: "Өч вакыйгадан соң Аллаһыга иман китерү кешелəргə файда бирмəс: "Кояшның көнбатыш тарафыннан чыгуы, Дəҗҗəлнең килүе, кешелəр белəн сөйлəшүче хайванның чыгуы." (Мөслим)

Аның чыгу урынына килгəндə Хузейфа ибн Асияд риваятендə ошбу хəдис зикер ителгəн: "Ул (кешелəр белəн сөйлəшүче хайван) Мəккə шəһəрендə урнашкан бөек мəчеттəн (ал-Харам) чыгар". Əлеге хайван җир йөзендəге кешелəргə мөһер сугар. (Иманлыларны имансыздан аерыр) Ошбу мөһердəн соң иманлы кешелəрнең йөзлəре тагын да нурланыр, иман китермəгəн кешелəрнең борыннарына мөһер сугылыр. Пəйгамбəребез əйтте: "Кешелəрнең (иман китермəгəн) борыннарына мөһер сугучы хайван чыгар. Һəм əлеге кешелəр шулкадəр күбəер ки, хəтта дөя сатып алган кеше дə: "Мин бу дөяне фəлəн борыны мөһерлəнгəн кешедəн алдым",- дип əйтер.

## ӨЧ УРЫНДА (КӨНБАТЫШТА, КӨНЧЫГЫШТА, ГАРƏП ЯРЫМУТРАВЫНДА) ҖИР ИШЕЛҮЕ

Пəйгамбəребез (с.г.с.) əйтте: "Кыямəт көненең ун галəмəте килмичə Кыямəт көне булмас... Өч урында (көнбатышта, көнчыгышта, Гарəп ярым утравында) җир ишелүе." Күпчелек галимнəрнең əйтүенчə əлегə ошбу җир ишелүлəр булмаган. Алар кыямəт көне алдыннан зур күлəмдə булырлар дигəн фикерлəр əйтелə.

## КЕШЕЛƏРНЕ ҖЫЕЛУ МƏЙДАНЫНА КУУЧЫ УТ

Пəйгамбəребез əйтте: "Ошбу галəмəтлəрнең ахыргысы булып кешелəрне җыелу мəйданына куучы Ямəн җиреннəн чыгачак ут булыр". Кайбер риваятьлəрдə əйтелгəнчə əлеге ут Хадрамаут диңгезе тарафыннан чыгар. Бүгенге көндə ошбу диңгезне Гарəп диңгезе дип атыйлар. Бу ут кешелəрне җир шарының һəр почмагыннан җыелу урынына куып алып килер. Əлеге вакыйга глобаль масштабта булыр һəм барлык җир йөзен чолгап алыр. Риваятьлəрдə күренгəнчə Кыямəт көне алдыннан барлык кешелəр Шəм (Сурия) җирлегендə җыелырлар. Ахмадтан (р.г.) риваять кылына: "Пəйгамбəребез Шəмгə (Сурия) таба ишарəлəп күрсəтте һəм: "Сез биредə җыелырсыз",–диде. Пəйгамбəребез (г.с.) əйтте: "Ут кешелəрне өч төркемлəп куыр: Аллаһ белəн очрашырга телəүчелəр, куркучылар (алар дөялəрендə икешəр, өчəр, дүртəр һəм унышар алмашып килерлəр, өченче төркемне ут артларыннан куалар һəм төп төркемнəн калышканнарны пешерер. Ут кешелəр ял итəргə туктаганда туктап торыр, кешелəр ял итеп кузгалгач янə алар белəн кузгалыр". (Бухари, Мөслим)

## МƏҺДИ КИЛҮЕ

Мəһди Фатыйманың углы Хəсəн нəселеннəн булыр. Аның исеме Мөхəммəд ибн Габдулладыр. Ул җиде ел хакимлек итəр, бу заманда җир йөзендə гаделлек һəм тугрылык булыр. Мəһди Мəдинə шəһəрендə туар. Яше кырыкка житкəч, үзен Мəһди итеп танытыр. Əмма шул сəбəпле Мəдинə шəһəрендə фетнə чыгар һəм ул Мəккə шəһəренə күчеп китəр. Шулвакыт дөньяның барлык читлəреннəн иң зур жиде галим үзлəре белəн өч йөз дə унҗидешəр кешене ияртеп, Мəһдине күрергə Мəккəгə юнəлерлəр. Əлеге төркем аны табып алгач ул кире Мəдинəгə кайтыр. Соңыннан килеп туган фетнəлəр сəбəпле тагын кире Мəккəгə китəр.

Шулвакыт халык аны Мəһди итеп таныр һəм аңа бəйгать биреп, үзлəренə имам итə. Кешелəр аның Мəһди икəнлеген исбатлаучы могҗизалар талəп иткəн чакта, кулына күктə очкан кошлар утырып, телгə килеп, аның хак имам икəнлеген исбатлар. Мəһди кайчан дөньяга килə дигəндə Имам Мөслим риваять кылган хəдистə Рəсүлебез (с.г.с.) əйтəдер: «Əл-Фурат (Гыйрактагы Ефрат елгасы) елгасы уртасында бер алтын тау пəйда булыр. Моны ишеткəн һəр адəм баласы шунда юнəлеп, алтынны алыр өчен бер-берсенең канын кояр. Йөз кеше китсə ки, аның туксан тугызы һəлак булыр һəм беркемгə дə бу алтын насыйп булмас. Ошбу вакыйгадан соң Мəһдинең чыгуын көтегез!». Мəһди үз гомерендə Пəйгамбəребезнең (с.г.с.) сөннəте илə хөкем итəр, җир йөзендə бəрəкəт һəм тынычлык хөкем сөрер. Шуннан соң, Мəһди Мəккə шəһəреннəн Бəйт аль-Макдискə, ягъни Фəлестыйн җирендəге изге мəчеткə һиҗрəт кылыр.

Һичшиксез, җир йөзендə хаҗ кылынганда, Коръəн укылганда, Аллаһы Тəгалəгə гыйбадəт кылынганда кыямəт көне житмəс. Аллаһы Тəгалə кыямəтнең вакытын төгəл белдермəсə дə, аның кечкенə һəм олы галəмəтлəрен безгə бəян кылды. Пəйгамбəребезнең (с.г.с.) бик матур бер хəдисе бар. Ул: "Иртəгə Кыямəт көне дисəлəр дə, кулыңда үсенте булса, шуны утырт",– ди. Шуңа күрə Кыямəт көненең килүен кул кушырып көтеп ятарга түгел, ə бəлки изгелеклəр кылып, аңа əзерлəнергə кирəк.

**ГАБДРАХМАН ХƏЗРƏТ ХƏБИБУЛЛИН**

# Намаз–сәламәтлек чыганагы

*Дөрес юлны*
*табыйм дисәң,*
*Намазларга бас бүген.*
*Сихәтләнеп киткәнеңне*
*Аңларсың шуннан үзең!*

"Кабат кубарылгач, кешеләрдән 5 төрле сорау соралмыйча аяклары баскан җирдән аерылмас",–дигән хәдис бар. Бу сорауларның икенчесе: "Сәламәтлегеңне нинди урынга сарыф иттең?" Безнең сәламәтлек–Аллаһы Тәгаләнең аманәт итеп биргән бүләге. Ә без аны кайларда сарыф иттек, ничек итеп сакладык һәм ныгыттык? Бирелгән сорауга билгеле бер дәрәҗәдә җавап була ала безнең иң төп гыйбадәтебез–намаз. Иң башта шуны әйтәсе килә, намазның сәламәтлеккә булган уңай игы безнең өчен төп сәбәп булырга тиеш түгел. Ә төп сәбәп булып тора–әлмисак, ягъни Аллаһы Тәгалә белән безнең җаннар арасындагы килешү. Ягъни Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән һәр кеше дөньяга фитрый иман белән килә. Бу инде хәзерге фән казанышлары белән исбатланган: 1) рентгенны компьютер ярдәмендә гарәп телендә укыдылар: уң як үпкә өстенә кан тамырлары белән язылган "Ләә иләәһә илләллаһ" кәлимәсе; 2) ә мөселман хирурглары йөрәк өстенә кан тамырлары белән гарәпчә язылган Аллаһ сүзен укыдылар. Түгәрәкләп әйткәндә, безнең намаз укуыбызның төп максаты җаннарыбызның (Америка галимнәре инфракызыл нурлар яктылыгында безнең җаныбызның тәннән аерылып чыгып киткәнен күзәттеләр) Аллаһы Тәгалә белән килешү нигезендә иманыбызга тугры булып калу. Ә хәзер югарыда әйтелгән сорауга җавап бирергә тырышабыз:

Намазда гарәп телендә укыла торган сүрәләр һәм зикерләр, һәм хәтта аерым хәрефләренә хәтле безнең сәламәтлекне ныгыта. Мәсәлән, "һә" хәрефе бугазның ерак төбеннән чыгу сәбәпле, бик яхшы күнегү сулауга булыша торган мускулларга. Моның хәзерге фән белән исбатланганын безгә Ирек хәзрәт җиткерде. Икенчедән, биш вакыт намаз уку (29+3=32 рәкәгать витр намазы белән) теләсә нинди физзарядканы алыштыра. Чөнки бер генә төр физкультура яки спортта кешенең 360 буыны да эшләми, ә намазда хәрәкәтләнмәгән бер генә буын да калмый. Икенче яктан белгечләр саусәламәт тәннең һәр буынына көнгә 300 хәрәкәт кирәк дип аңлаталар. Бу сорау буенча намаз бик яхшы булыша.

Иң әһәмиятле сорауларның берсе-чисталык. Ә үз чиратында чиста мохит теләсә нинди авыруга зур гына киртә...Тәһарәтсез намаз башланмый. Шәригатьтә киемне, мәчет һәм мәдрәсәгә укырга бару һәм башка эшләр дә мәкруһ була. Ягъни, тискәре энергия безнең сәламәтлеккә зыян сала. Гомумән, без һәрвакыт госелле булырга тиеш;

3) без ике аякны иртән һәм кич суык су белән юып, тәһарәтне тәмамлыйбыз. Ә бу безнең эчке әгъзаларыбызның суыкка бирешмәү дәрәҗәсен үстерә икән. Ничек? Аяк табанына килгән нерв җепләре һәм эчке органнарга барган нерв җепләренең башлануы безнең баш мие тиресенең бер үк районында булу сәбәп-



ле, ягъни без бер үк вакытта эчке әгъзаларны да суык су белән юабыз булып чыга...

тәнне һәм намаз урынын зур вә кечкенә нәҗестән пакьлау шарт. Теория һәм практикага артык тукталмый гына зур һәм кечкенә тәһарәтләрнең фарыз һәм сөннәтләре үтәлгән вакытта без чиста су белән юынабыз, тәннең билгеле бер өлешләрен сыпырабыз һәм ышкыйбыз (массаж), авызны, тамак төбен һәм борынны өч мәртәбә үзенең алымнары белән юабыз һәм чайкыйбыз. Яхшылап сөртенәбез (массаж). Менә бу гамәлләрне башкарганда безнең сәламәтлеккә бетмәс-төкәнмәс файда килә. Шуларның берничәсенә генә тукталып китәм:

1)табиблар әйтүе буенча авызны, тамак төбен һәм борын эчен чайкау грippка гына киртә түгел, ә башка авыру микробларына каршы тору алымы да;

2) гөсел билгеле булган Иванов системасы белән ярыша ала. Икенче яктан гөселсез намаз уку гына түгел, ә ашарга әзерләү, ашау-эчү,

4) Медицина әйтүе буенча, кем кече йомыштан соң һәрвакыт истинҗа ала, ул геморрой дигән авыруны кисәтә...

5) Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән бик зур әһәмияткә ия юына торган суыбызның һәр тамчысы үзенә сеңдерә билгеле бер дәрәҗәдә безнең тәндәге тискәре энергияне яки кылган гөнаһларыбызны. Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә әйтә: "Тәһарәт алганда тамган һәр тамчы су саен кешенең гөнаһы кими". Җәмгыять чиста тәнле һәм сәламәт рухлы кешеләр белән генә көчле. Ә аның өчен безнең саусәламәт калебтә җаныбыз тиешле тәртиптә гыйбадәтләребез белән пакьләнгән булырга тиеш.

**(Ахыры киләсе санда).**

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ,**
**мәдрәсә шәкерте, Халыкара "Канатлы арыслан" ордены кавалеры.**

## Сорау-җавап

**Сорау: сәҗдәи сәһү ничек һәм кайсы вакытларда кылына?**

**ҖАВАП:** Фикх китабында утыз урында сәҗдәи сәһүне кылырга кирәклеге турында әйтелә. Ләкин бөтен очраклар да өч мөһим кагыйдәгә буйсыналар:

Беренчедән, әгәр мөселман намазына берәр фарыз гамәлне кушса (әйтик, тагын бер рәкәгать кушса), ул сәҗдәи сәһүне кылырга тиеш. Икенчедән, берәр вәҗиб гамәл төшеп калса, бу сәҗдә кылына. Өченчедән, әгәр намаз укучы өстәмә вәҗиб гамәл кылса, ул сәҗдәи сәһүне кылырга тиеш. Намаз укучыга түбәндәгене җиткерергә кирәк: әгәр ул намазында берәр фарыз (мәҗбүри) гамәлне төшереп калдырса, ул намазын яңадан укырга тиеш. Мәсәлән, әгәр ул бер рәкәгатьне төшереп калдырса, сәҗдәне яки рөкүгне кылмый калдырса. Әгәр инде бер фарыз гамәлне кушса, аның намазы бозылмый, ләкин ул сәҗдәи сәхүне кылырга тиеш. Андый мисалларны күп китерергә була. Әйтик, бер рәкәгатьтә ике рөкүг яки өч сәҗдә кылу, бишенче рәкәгатькә торып басу.

Әгәр намаз эчендәге вәҗиб гамәлгә килсәк, кеше аны төшереп калдырса да, тагын бер вәҗиб гамәлне кушса да, сәҗдәи сәхүне кылырга тиеш. Зул-Ядәйн җиткерә: "сәҗдәи сәһү әттәхиятне укыгач кылына. Сәлам биргәч, ике сәҗдә кылына, соңыннан әттәхият тә, салават та укыла.

Соңыннан исә намазны тәмамларга кирәк. Намазның ахырында сәҗдәи сәһү кылачак кеше, онытып, кылмый калдырса, намазына кимчелек килмәс аның өчен намаздан соң һичбер гамәл кылу лязем булмас. Әгәр инде кеше әле намазын тәмамламаса, ул сәҗдәи сәһүне кылырга тиеш.



# Гыйлем һәркемгә фарыз

Ислам кануннары буенча яшим, бәхетле булыйм, рухи байлыгымны арттырыйм дигән кешегә бүгенге көндә бөтен мөмкинлекләр дә бар. Мәчет-мәдрәсәләр эшләп тора, өйрәним дигән кешегә җитәрлек дәрәҗәдә дини басмалар, радио, ТВ, интернет та бар. Кызганычка каршы аларда бер үк сорауга җаваплар да төрле, бер-берсенә каршы, тәгәл булмаганнары да очрый. Аннан соң без балачактан ук дин кушканча үтәргә өйрәтелмәгән буын, без үскән җәмгыять безне диннән биздерергә тырышты. Шуның өстенә әле без, гарәпчә укый-яза белгән, сабыр, тыйнак, шәригать кануннары буенча гомер иткән әби-бабаларыбыздан да вакытында дини гыйлем алу мөмкинлеген дә кулдан ычкындырганбыз.

Ничек итеп дөрес дини гыйлем алырга? Бу сорау күпләрнең күңелен борчыйдыр мөгаен, чөнки иманлы булу һәр кешенең үз ихтыярына куелган. Дини белемебезнең бик тә чамалы, юк дәрәҗәсендә икәнлеген мин, минем курсташларым Мамадыш мәдрәсәсенең 1нче курсына укырга йөри башлагач та төшендек. Мәдрәсәдәге мохит, уку өчен бөтен уңайлыклары, шәкертләр өчен актив тормыш алып бару мөмкинлеге бездә уку теләген тагын да арттырды.

Укый башлагач та мине иң гаҗәпләндергән һәм шикләндергән, шул ук вакытта куандырган ике нәрсә булды: ничек инде безнең остазларыбыз–безнең балаларыбыздан да яшьрәк һәм яшь кенә булуларына карамастан, алар кайда һәм кайчан дини белемнәрне үзләштерергә өлгергәннәр?!

Әлһәмдүлилләһ, уку дәверендә бу шикләнүләребез юкка чыкты, нәкъ менә шушы яшь кенә мөгаллим-мөгаллимәләр Ислам диненең асылына төшендерә алдылар да инде. Мәдрәсәдә алган гыйлемне башка уку йортларында алган белем белән һич кенә чагыштырып булмый. Монда алган дини белем безнең күбебезнең дөньяга, тирә-юньгә, табигатькә карашын, яшәү рәвешендә үзгәртте дисәм ялгыш булмас.

Безнең өчен, шушы кыска гына 3 ел эчендә Коръән Кәримне кулга алып, аны дөрес итеп укырга өйрәнү, фикх, гакыйдә, тәфсир фәннәрен, гарәп телен үзләштерү җиңел булды дип әйтеп булмый.

Шуңа күрә алган гыйлемнәребезне камилләштерү өчен мәдрәсәдә тагын бер мөмкинлек бар: без атнага 1 тапкыр укып китә алабыз. Нинди генә сорау белән килсәк тә, монда Коръәни Кәримгә һәм хәдисләргә нигезләнгән төпле җаваплар гына ишетәбез.

Мәдрәсәдә уку-укыту программасы төрле эчтәлекле, нәтиҗәле чаралар белән бәйләнеп алып барыла. Бүгенге көндә мәдрәсә базасында “Ак Калфак” хатын-кызлар клубы, балалар лагерьлары эшли. Коръән уку бәйгеләрен, ачык дәресләр, хәйрия акцияләрен, ай саен имамнарның һәм абыстайларның белемнәрен күтәрү курсларын оештыру да кеч-кенә генә коллектив өстендә икәнен белгәч , аларны Аллаһы Тәгалә рәхмәтеннән ташламасын диясе генә кала. Инде менә ике елга якын мәдрәсәнең айлык дини-иҗтимагый газетасы “Нәсыйхәт” һәрберебезнең көтеп алынган басмасына әйләнде. Газета да шушы ук коллективның иҗат җимеше, аларга уңышлар гына юлдаш булса иде.

Мәдрәсәнең эшчәнлеге күпкырлы, проблемалары да җитәрлектер. Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам, бер хәдисендә: “ Белем алу һәр мөселманга фарыз дигән. Ислам дине нигезләре буенча башлангыч белем алам дигән һәркем: олы яшьтәге әби-бабайлардан алып төрле яшьтәге мәктәп балалары мәдрәсәгә укырга йөреп фәкать файдалы белемгә генә ия булачак. Ә монда югары әхлаклы, дини һәм доньяви белемнәрен һәрдаим камилләштереп торучы, үз эшләрен яратып башкаручы, динебезне күтәрү өчен бөтен мөмкинлекләрне булдыру өстендә эшләүче мөгаллимнәргә шушы изге эшләрендә уңышлар, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булсын!

**САТТАРОВА Р.**
**мәдрәсәнең 1нче курс талибәсе**

## Игъланнар:

***1нче гыйнвардан Мамадыш мәдрәсәсе “Иң яхшы шәкерт” бәйгесе игълан итә.** Әлеге бәйгенең максаты: дини гыйлем бирүне көчәйтү, популярлаштыру, студентларның белем сыйфатын яхшырту, укытучыларның белгечлек дәрәҗәсен арттыру, студентларны төрле иҗтимагый чараларда катнашуга кызыктыру. Бәйгенең нәтиҗәләре һәр ай азагында билгеләнеп торачак. Җиңүчеләрне бүләкләр көтә.

***“Нәсыйхәт” газетасы ислам тематикасына багышланган “Иң яхшы дини мәкалә” һәм “Иң яхшы дини шигырь” дип аталган конкурс игълан итә.** Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә. Һәр катнашучының иҗади җимешләре безнең газетабызда бастырылачак. Аларны мәдрәсәнең электрон почтасына яки хат рәвешендә җибәрүегез мөмкин.

***Мамадыш мәдрәсәсе ял курсларына укучылар җыя.** Укулар һәр атнаның якшәмбесендә 9:00-13:00 сәгатьләрдә дәвам итәчәк. Яшь категориясе чикләнмәгән. Барлык укырга теләүчеләрне мәдрәсәбездә көтәбез.

***Мамадыш мәдрәсәсе читтән торып уку бүлегенә укучылар җыя.** Укулар елга ике мәртәбә (1-10 гыйнвар һәм 20-30 апрель) 10 көн дәвамында мәдрәсәдә белем алачаклар. Торак һәм ашау-эчү каралган.

**Белешмәләр өчен телефон: 89172802391; 3-19-17**

## Шигъри дулкында

### Хәмер – шайтан азыгы

Җирдә яшәлгән һәрбер
көнебез –
Барчабызга Аллаһ
бүләге.
Чәркә күтәреп матур
сүзләр әйтү –
Адәмнәргә шайтан теләге.
Тост әйтелде–әйдә
күтәрдек!
(Иблис кушканны
бик тиз үтәдек.)
Фәрештәләр кача,
кыза тантана,
Аллаһ хозурына
бармый теләкләр,
Шайтан: “Җиңдем!”-
диеп мактана.
Хәмерсез булмый,
әле туктау юк! –
Шайтан тора
һәрчак котыртып.
Менә шулай
җиңел була диеп,
Кайчак “бау” да
куя тоттырып.
Аллаһ каршы
булган гамәл белән
Теләкләр, һай,
чынга ашармы?
Хәмерсез булмый–
нигә ният шундый,
Гөнаһ кылмыйча
яшәү начармы?
Арыныргa ашыгыйк
шайтан тозагыннан,
Иманны нгытып
котылыйк йозагыннан.
“Бисмилла” әйтеп
башлыйк теләкләрне,
Фәрештәләр
торсын “Амин” дип.

**БИКТИМИРОВ ГӘБДЕЛХӘЙ**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 250 данә.**